Лельвиж авыл җирлеге Советы

# КАРАР

22 март, 2024 ел №11

**Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Лельвиж авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лельвиж авыл җирлеге Уставы нигезендә Лельвиж авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 04 апреленә 9 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Лельвиж авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 04 апреленә 14 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Лельвиж авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

3. 2024 елның 04 апреленә 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Лельвиж авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру
- Лельвиж авылында, юлларга вак таш салып, чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту;
- трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау
- урам яктыртуны карап тоту (Лельвиж авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм ремонтлау)
- Лельвиж авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;
- мотопомпа сатып алу
- Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү
- спорт инвентаре сатып алу
- Авыл көне бәйрәме үткәрү?

2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын,

скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау *(материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре); (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру; (Лельвиж авылында су суыртү манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү)*

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү *(Лельвиж авылы чишмәләрен тоту, ремонтлау, төзекләндерү чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре; проект-смета документлары, эшләү, килешү буенча түләү)*

җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту *(Лельвиж авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка эш төрләре) (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);*

- торак пункт территориясен төзекләндерү *(Лельвиж авылы территориясен төзекләндерү, җәен печәнен чабу һәм кышын кардан арындыру, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),*
*(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);*
*(трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);*

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (*мотопомпа сатып алу)*

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы: Э.Ю. Игнатьева